**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5755**
**08.11.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 нче, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 нче, 2017 елның 8 февралендәге 588 нче, 2017 елның 3 маендагы 2747 нче, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 нче, 2018 елның 18 июлендәге 4000 нче, 2018 елның 27 июлендәге 4226 нчы, 2018 елның 2 августындагы 4343 нче, 2018 елның 22 ноябрендәге 6940 нчы, 2019 елның 5 мартындагы 1144 нче, 2019 елның 23 маендагы 2663 нче карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, аны түбәндәге эчтәлектәге 86 пункт белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«86. Биналарның фасадларына өстәмә җиһаз урнаштыру буенча архитектура йөкләмәсе әзерләү.»

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге караны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин